КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 май г.Казань № 317

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче; 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы; 2022 ел, 13 декабрь, 1319 нчы; 2022 ел, 21 декабрь, 1389 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 168 нче; 2023 ел, 4 июль, 786 нчы; 2023 ел, 9 август, 961 нче; 2023 ел, 5 октябрь, 1239 нчы; 2024 ел, 4 март, 119 нчы; 2024 ел, 17 апрель, 258 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Саклагычлар төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән элиталы орлыкчылыкка ярдәм итүгә һәм (яисә) орлыклар сатып алуга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирү нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге субсидия бирү нәтиҗәләре кулланыла:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә – 31 декабрьгә карата агымдагы финанс елында элиталы орлыклар (орлык бәрәңгенең оригиналь һәм элиталы чәчүлекләре һәм (яисә) яшелчә культураларының орлык чәчүлекләре белән

чәчелгән чәчү мәйданыннан тыш) чәчелде;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә – 31 декабрьгә карата агымдагы елда Федераль фәнни-техник программа кысаларында җитештерелгән орлыклар (бәрәңге һәм яшелчә культуралары орлыкларыннан тыш) сатып алынды һәм чәчелде.»;

әлеге карар белән расланган Махсуслаштырылган ит токымнарының мөгезле эре терлекнең (нәселле терлектән тыш) ана товар баш санын асрауга ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен субсидияләр бирүнең түбәндәге нәтиҗәсе кулланыла: агымдагы финанс елның 31 декабренә карата махсуслаштырылган итле токымлы мөгезле эре терлекнең (нәселле терлектән тыш) ана товар баш саны (мең баш) агымдагы финанс елының 1 гыйнварына карата махсуслаштырылган итле токымлы мөгезле эре терлекнең (нәселле терлектән тыш) ана товар баш саныннан кимрәк булмауга ирешелде.»;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгын иминләштерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирү нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге субсидия бирү нәтиҗәләре кулланыла:

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә – субсидия бирү елының 31 декабренә карата чәчү (утырту) мәйданы (мең гектар) иминләштерелде;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә – субсидия бирү елының 31 декабренә карата авыл хуҗалыгы хайваннарының баш саны (мең шартлы баш саны) иминләштерелде;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә – субсидия бирү елының 31 декабренә карата товар аквакультурасы (товар балыкчылыгы) объектларын җитештерү күләме (мең тонна) иминләштерелде.»;

әлеге карар белән расланган Бөртекле, кузаклы ашлык, майлы (рапс һәм соядан тыш), азык авыл хуҗалыгы культураларын җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен субсидияләр бирүнең түбәндәге нәтиҗәсе кулланыла: агымдагы елның 31 декабренә карата агымдагы ел уңышы өчен бөртекле, кузаклы бөртекле, майлы (рапс һәм соядан тыш) һәм азык авыл хуҗалыгы культуралары утыртылды (гектар).»;

19 пунктның уналтынчы абзацында «48» саннарын «47» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Сөт җитештерүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен субсидияләр бирүнең түбәндәге нәтиҗәсе кулланыла: узган финанс елының шул ук чоры белән

чагыштырганда, агымдагы финанс елында 31 декабрьгә карата сөт 100 яки аннан күбрәк процент дәрәҗәсендә җитештерелде (мең тонна).»;

19 пунктның уналтынчы абзацында «48» саннарын «47» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

15 пунктның беренче – бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирү нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге субсидия бирү нәтиҗәләре кулланыла:

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә – авыл хуҗалыгы хайваннарының нәселле нәселле ана терлекләре санына ел 31 декабренә кадәр субсидия бирү елыннан алдагы елның 31 декабренә кадәр булган чорда нәселле ана терлекләренең кимендә факттагы баш саны дәрәҗәсендә субсидияләр бирү шарты белән кабат исәплэгәндә ирешелде;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә – субсидия бирү елының 31 декабренә карата нәсел сыйфаты буенча бәяләнгән яисә әлеге сыйфатны (башларны) бәяләү процессында булган нәселле үгезләр саны сибсидия бирү елына кадәрге елның 31 декабренә карата нәсел сыйфаты буенча бәяләнгән яисә әлеге сыйфатны бәяләү процессында булган нәселле үгезләр-җитештерүчеләрнең факттагы баш саныннан ким булмаган дәрәҗәдә ирешелде;

әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә:

сатып алу датасына шартлы баш санына (мең баш саны) күчереп исәпләгәндә дәүләт нәсел регистрында теркәлгән нәселле хуҗалыклардан сатып алынган авыл хуҗалыгындагы нәселле яшь терлекләр санына ирешелде;»;

19 пунктның уналтынчы абзацында «48» саннарын «47» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Чи мөгезле эре терлек, кәҗә һәм сарык сөтен азык-төлек продукциясенә эшкәртүгә ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен субсидияләр бирүнең түбәндәге нәтиҗәсе кулланыла: субсидия бирү елында 31 декабрьгә карата чи мөгезле эре терлек, кәҗә һәм сарык сөтен азык-төлек продукциясенә (мең тонна) эшкәртелде.»;

әлеге карарга Саклагычлар төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин